ГЛАВА ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ

РАСПОРЯЖЕНИЕ                                        БОЕРЫК

______________ с. Верхний Услон ______________

Югары Ослан муниципаль районы буенча Халыкара коррупциягә каршы көрәш көненә багышланган чаралар планын раслау турында

Коррупциягә каршы дөньякүләм караш формалаштыру, Халыкара коррупциягә каршы көрәш көненә әзерләнү һәм үткәрү белән бәйле рәвештә, гражданнарның хокукый аң дәрәҗәсен һәм хокукый культурасын күтәрү мәсьәләләрен хәл итү максатларында:

1. Югары Ослан муниципаль районы территориясендә 2021 елның 1 декабреннән 10 декабренә кадәр Халыкара коррупциягә каршы көрәш көненә багышланган чаралар үткәрергә.

2. Югары Ослан муниципаль районы буенча Халыкара коррупциягә каршы көрәш көненә багышланган чаралар планын (алга таба – План, 1 нче кушымта) расларга.

3. Җирле үзидарә органнары һәм оешмалар җитәкчеләренә, милек рәвешләренә карамастан, Планда каралган чараларны җаваплы башкаручылар булып торучы оешмаларга План чараларын әзерләүне һәм үткәрүне оештырырга тәкъдим итәргә.

4. «Татмедиа» АҖ филиалы җитәкчесенә - «Волжская Новь» газетасы баш мөхәрриренә район газетасында План чараларын яктыртуны тәэмин итәргә киңәш итәргә.

5. Әлеге күрсәтмәнең үтәлешен тикшереп торуны Югары Ослан муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесенә йөкләргә.

Югары Ослан муниципаль районы Башлыгы                М. Г. Зыятдинов

Югары Ослан муниципаль районы
Башлыгының ____________
____ номерлы боерыгына
1 нче кушымта

Югары Ослан муниципаль районы буенча Халыкара коррупциягә каршы көрәш көненә (9 декабрь) туры китерелгән Чаралар планы

| № т/б | Чара | Үткәрү датасы һәм вакыты | Җаваплы башкаручылар |
|---|---|---|---|
| 1. | Коррупция мәсьәләләре буенча район халкыннан сораштыру | 2021 елның 1-10 декабре | «Татмедиа» ААҖ «Волжская Новь» газетасы редакциясе |
| 2. | Район халкы арасында, Югары Ослан авылының үзәк мәйданында коррупция алшартлары һәм аларны булдырмау чаралары турында мәгълүмат тупланган листовкалар тарату | 01.12.2021 | «Югары Ослан муниципаль районы Туган якны өйрәнү музее» МБУ |
| 3. | Тематик плакатлар, стена газеталары һәм мәгълүмати стендлар рәсмиләштерү | 2021 елның 1 декабреннән 10 декабренә кадәр | «Югары Ослан муниципаль районы мәдәният бүлеге» МКУ, «Югары Ослан муниципаль районы мәгариф бүлеге» МКУ |
| 4. | Коррупция темасына мәгълүмати сәгатьләр, профилактик әңгәмәләр, ачык дәресләр, мәктәп укучылары һәм район халкы белән дискуссияләр үткәрү | 2021 елның 1 декабреннән 10 декабренә кадәр | «Югары Ослан муниципаль районы мәдәният бүлеге» МКУ, «Югары Ослан муниципаль районы мәгариф бүлеге» МКУ |
| 5. | Өлкән сыйныф укучыларының хокук саклау органнары, иҗтимагый оешмалар һәм җирле үзидарә органнары вәкилләре белән коррупция темасына очрашулары | 2021 елның 1 декабреннән 10 декабренә кадәр | «Югары Ослан муниципаль районы мәгариф бүлеге» МКУ |
| 6. | Коррупциягә каршы тематикага педагогик советлар үткәрү | 2021 елның 1 декабреннән 10 декабренә кадәр | «Югары Ослан муниципаль районы мәгариф бүлеге» МКУ |
| 7. | Коррупциягә каршы тәрбия буенча мәктәп укучылары белән сыйныфтан тыш эш оештыру (әңгәмәләр, рольле уеннар, ата-аналар, хокук саклау органнары вәкилләре катнашында сыйныф сәгатьләре) | 2021 елның 1 декабреннән 10 декабренә кадәр | «Югары Ослан муниципаль районы мәгариф бүлеге» МКУ Район Башкарма комитетының Яшьләр эшләре һәм спорт |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | бүлеге |
| 8. | Халыкны социаль сораштыру һәм "Без - коррупциягә каршы!" ролигын эшләү; мәктәп укучылары һәм яшьләр арасында "Нәрсә ул коррупция" дигән анкета уздыру. | 2021 елның 1 декабреннән 10 декабренә кадәр | «Югары Ослан районының Мәдәният бүлеге» МКУ |
| 9. | Коррупциягә каршы тематика буенча балалар рәсемнәре, плакатлар, карикатуралар конкурслары һәм күргәзмәләрен оештыру. | 2021 елның 1 декабреннән 10 декабренә кадәр | «Югары Ослан муниципаль районы мәдәният бүлеге» МКУ,<br>«Югары Ослан муниципаль районы мәгариф бүлеге» МКУ |
| 10. | Язылучылар һәм кунаклар өчен korguzinsky_sdk «Без-коррупциягә каршы!» социаль ролигын урнаштыру - | 9 декабрь 2021 ел | «Югары Ослан районының Мәдәният бүлеге» МКУ |
| 11. | Коррупция темасына халык арасында мәгълүмати буклетлар һәм листовкалар әзерләү һәм тарату | 2021 елның 1 декабреннән 10 декабренә кадәр | «Югары Ослан районының Мәдәният бүлеге» МКУ, район Башкарма комитетының Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге |
| 12. | Районның рәсми сайтында, белем бирү учреждениеләрендә коррупциягә каршы юнәлештәге чаралар турында мәгълүмат урнаштыру | Үткәрү чорында | Мәгълүматлаштыру бүлеге, җаваплы башкаручылар |
| 13. | Халыкара коррупциягә каршы көрәш көне кысаларында үткәрелә торган «Волжская Новь» газетасында район чараларын яктырту | Үткәрү чорында | «Татмедиа» ААҖ «Волжская Новь» газетасы редакциясе |